| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КУЧУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КӨЧЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.05.2021 с. Нижнее Кучуково № 6

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге торак пунктларын янгынга каршы яклауны ныгыту максатларында чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм әйберләрне яндыру урынын һәм ысулын билгеләү турында

Торак пунктларны янгынга каршы яклауны ныгытуга юнәлдерелгән муниципаль хокукый актлар кабул итү максатларында, шул исәптән «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы, «Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 23 апрелендәге 5 пунктындагы 12 абзацы нигезендә «Янгын куркынычсызлыгы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 маендагы 1866-XII номерлы карары, «Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән, Әгерҗе районы Көчек авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге торак пунктларын янгынга каршы яклауны ныгыту максатларында чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм әйберләрне яндыру урынын һәм ысулын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында - http://agryz.tatarstan.ru урнаштырырга һәм веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кучук авыл җирлеге мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе Р.Ә. Нурмөхәммәтов

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Көчек авыл җирлеге
Башкарма комитетының
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы**
**Көчек авыл җирлегенең торак пунктларын янгынга каршы яклауны ныгыту максатларында чүп-чарны, үләннәрне, яфракларны, материалларны, эшләнмәләрне башка калдыкларны яндыру**
**ысулы һәм урыны**

1. Торак пунктларның гомуми кулланылыштагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан хосусый йорт биләмәләрендә учаклар кабызу, махсус билгеләнгән һәм җиһазландырылган урыннардан тыш, азык әзерләү өчен ачык ут куллану, шулай ук әлеге кушымтаның 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән урыннардан һәм ысуллардан тыш, чүп, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яисә эшләнмәләр яндыру тыела.

2. Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яндыру урыны итеп түбәндәге территорияләрне билгеләргә:

| № п/п | Авыл җирлеге торак пункты исеме | Чүп-чар, үләннәр, яфраклар һәм башка калдыклар, материаллар яки эшләнмәләр яндыру урыны | Җаваплы затлар |
|---|---|---|---|
| 1. | Түбән Көчек авылы | Вәркләд елгасы яры буенда, Тукай урамы ахырында, 78 нче йорттан соң 500 метр читтә, трактор белән сөрелгән | Көчек авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ә. Нурмөхәммәтов |
| 2. | Вәрклед-Бодья авылы | чишмәдән ерак түгел җирдә, торак пункттан 500 метр ераклыкта, трактор белән сөрелгән. | Көчек авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ә. Нурмөхәммәтов |
| 3. | Рус Шаршадасы авылы | Болын урамы артындагы 30 номерлы участок артындарак, торак пункттан 500 метр читтә, кырда, трактор белән сөрелгән. | Көчек авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ә. Нурмөхәммәтов |

3. Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яки эшләнмәләрне яндыру ысулын урнаштыру - ачык учак.

4. Ачык утны куллану урыны:

- якындагы объекттан (биналар, корылмалар, ачык склад, скирдлар) кимендә 50 метр читтә, парк зонасыннан 100 метр ераклыкта яки аерым үсүче ылыслы һәм яфраклы агачлардан һәм яшь агачлардан яисә агач төркемнәреннән 100 метр ераклыкта урнашырга тиеш;

- ачык ут куллану урыны тирәсендәге территория 10 метр радиуста коры-сары агачлардан, коры үләннән, бура калдыкларыннан, башка ягулык материалларыннан чистартылырга һәм 2 метрдан ким булмаган киңлектәге янгынга каршы, минеральләштерелгән полоса белән бүленергә тиеш;

- ачык ут кулланучы зат янгын сүндерү өчен инвентарь белән тәэмин ителергә тиеш: чиләк, көрәк, су белән мичкә, комлы тартма, янгынны локальләштерү һәм бетерү өчен, шулай ук янгын сүндерү бүлекчәсен чакыру өчен мобиль элемтә чарасы.

5. Чүп-чар, үләннәр, яфраклар, агач әйберләр һәм башка калдыклар, материаллар яки эшләнмәләр яндыру, җил тизлеге секундына 5 метрдан артмаган очракта гына эшләнелә.

6. Әлеге кушымта Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертелгән чорда гамәлдә түгел.